ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет ур.,16 нче йорт, Килди авылы,
422586

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.03.2020 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. 7

с. Кильдеево

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында»

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирүче халәткә китерү һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын вакытлыча башкаручы 2020 елның 4 мартындагы 157 номерлы карарын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм санитар-экологик чистарту икеайлыгын (алга таба - икеайлык) игълан итәргә.
2. 2020 елга Килди авыл җирлегенең төзекләндерү комитеты составын расларга (1 кушымта).
3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәрге икеайлык кысаларында санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту чаралары планын (2 кушымта) расларга.
4. Килди авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына карамастан, якын-тирә территорияләрне санитар чистарту эшен оештырырга, икеайлык кысаларында оештырылган полигонга һәм чүплеккә каты көнкүреш калдыклары чыгару өчен йөк транспорты бүлеп бирергә тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, фасадларны һәм биналарны ремонтлау эшен оештырырга.
5. Килди авыл җирлеге территориясендә нинди хокукка карамастан күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Килди авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

7.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесенең 2020 елның 27 мартындагы 7 номерлы карарына

1 кушымта

Килди авыл җирлеген төзекләндерү буенча
комитет составы

1. Бурдин Виктор Михайлович – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башлыгы
2. Лёвочкина Наталья Николаевна – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе
3. Федоров Василий Петрович – полиция майоры, Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең ОУУП һәм ПДН полиция участок вәкаләтле вәкиле.
4. Гаврилина Галина Александровна – Килди ФАП фельдшеры.
5. Токсарова Галина Николаевна – ГАУЗ «Югары Ослан ҮРХБ», шәфкать туташы.
6. Лазарев Виталий Николаевич – Уланово авылы старостасы.
7. Хваткова Елена Анатольевна – 6 номерлы Уланово сайлау округы депутаты.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2020 елның 27 мартындагы
7 номерлы карарына
2 кушымта.

2020елгы икеайлык кысаларында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге территориясендә санитар-экологик хәлне яхшыртуга юнәлдерелгән төзекләндерү һәм санитар чистарту чаралары
ПЛАНЫ

| Т.б. № | Чараның исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Килди авыл җирлеге территориясендә чүплекләрне ачыклау һәм бетерү | 01.04.2020 - 01.05.2020 | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 2. | Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларның һәйкәлен төзекләндерү | 20.04.2020 - 06.05.2020 | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 3. | Килди авыл җирлеге буенча торак пунктлар эчендә баганалар агарту | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 4. | Торак пунктлар территорияләрен чүп-чардан җыештыру | Даими | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты оешмалар |
| 5. | Уборка придомовых территорий частных жилых домов | Даими | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты, халык |
| 6. | Зиратлар территорияләрен төзекләндерү | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты, халык |
| 7. | Чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 8. | 100 урынга исәпләнгән КФҮ территориясен төзекләндерү | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты Килди СДК |
| 9. | Урамнарны яктырту (ремонт, өстәмә яктырткычлар урнаштыру) | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 10. | Килди авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11. | Клумбалар ясау һәм ремонтлау, чәчәкләр утырту | 30.05.2020 елга кадәр | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты, оешмалар |
| 12. | Юл кырыйларын һәм юл буйларын чабу | Даими | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| 13. | Күперләрне ремонтлау | Май | Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты, халык |

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин